СОВЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 2а, д.Нижние Аты,
Арский муниципальный район, 422016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 2а йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)50-7-35, факс (84366)50-7-35 E-mail: Sa.tArs@tatar.ru

Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

18 июль 2023 ел　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ 104

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты җирлеге генераль планын әзерләү кирәк булмау турында» 10.02.2022 № 54 Урта Аты авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге территориясендә җирлек территориясеннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмавын исәпкә алып, комплекслы социаль-икътисадый үсешнең расланган программасы юк һәм Татарстан Республикасы һәм Арча муниципаль районының территориаль планлаштыру схемаларында федераль, региональ һәм җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру каралмаган, Татарстан Республикасы Урта Аты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Урта Аты муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге генераль планын әзерләү кирәк булмау турында» 10.02.2022 № 54 Урта Аты авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктта «2022 елның 30 декабренә кадәр» сүзләрен «2023 елның 30 декабренә кадәр» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның «01» гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (arsk.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

СОВЕТ СРЕДНЕАТЫНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　Батталова.Р.Х